# Күңелендә аның җылы кояш

**Егерме икенче мартта ике “5”ле алу уңаеннан уздырылган бәйрәменә шулкадәр күп халык җыелыр дип уйламагандыр да Рәкит. Ә бит гомер чаба гына! Чаллы шәһәрендә эшли башлавына гына да 32 ел вакыт узып киткән. Шушы вакыт эчендә күпме каршылыклар үтелгән, күпме җиңүләр яулангән!**



Йолдызларга очар хыяллар белән янганда, сөенеч-куанычлар тулы күңелен кара кайгыга батырырга теләгәндәй, бәхетсезлек ишек шакыган. Ләкин шигъри җанлы, тормышка баш-аягы белән гашыйк егет егылмый. Тикмәгә генә аны “татар Маресьевы” дип атамаганнар шул. Рәкит Әбделманов, үзе турында кайгырту урынына, башкаларга ярдәм итү хакында уйлый. Язмыш тарафыннан тез астына сугылганнарның тормышын җиңеләйтү өчен ал-ял белми эшли. Инвалид спортчыларга иганәчелек итүче “Идел — Урал” фондын төзи. Атларда, велосипедларда ерак араларга ничәмә-ничә сәяхәтләр ясала, инвалидлар өчен Сабантуйлар, кул көрәше ярышлары уздырыла, шахмат бәйгеләре оештырыла... Саный китсәң, башкарылган эшләрнең исәбе-саны, очы-кырые юк. Болар гынамы әле! Инвалидларга эш урыннары булдыру артыннан да чаба Рәкит. Киез итек басу цехы ачып җибәргәч, күңелендә нинди гөлләр чәчәк атканын ул үзе генә белә! Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Рубис абый Зарипов та Рәкит оештырган чараларда күп мәртәбәләр катнашкан икән. “Аның ихтыяр көченә нык гаҗәпләндем, оста оештыручы булуын күреп сокландым, бик тә саваплы эш башкаруына сәяхәтләр вакытында чын-чынлап инандым!” — диде ул. Рәкит Җәүдәт улы Әбделмәнов хөрмәтенә оештырылган кичәне ямьләп, Рубис абый татар халык җыры “Әй гүзәлем!”не башкарды. Чаллы каласында гына түгел, бөтен Татарстан күләмендә зур ихтирам яулаган сүз остасы, милли кичәләрнең даими алып баручысы Гөлзада ханым Рзаеваның чыгышы йөрәкләрне чемердәтте. “Татарда “Итәгенә ут төшмәгән генә белми” дигән гыйбарә йөри, — диде ул. — “Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә” дигәне дә бар. Үземнең улым фаҗигага юлыккач, тагын да тирәнрәк тойдым инвалидларның никадәр көчле рухлы икәнен!..”

Юбилярны котлап сүз әйтергә теләүчеләр бик күп булды. Әгәр барысына да сүз бирсәң, кичә тагын берничә сәгатькә сузылыр иде. Шәһәр хакимиятеннән, ветераннар советыннан, мәдәният бүлегеннән, физкультура-спорт идарәсеннән, сукырлар җәмгыятеннән, төрле уку йортларыннан, татар-башкорт дуслыгы оешмасыннан бер-бер артлы тәбрикләүчеләр күтәрелде. “Ләйсән” әдәби берләшмәсеннән Роза Хәмидуллина җитәкчелегендә Амур Фәләх, Айрат Суфиянов, Галиәхмәт Шаһи, Марс Яһудин, Айрат Шәйхетдинов, Фәнис Нуретдиновлар да иҗатташ дусларын котларга килгәннәр.

Күпчелек котлауларга музыкаль ноктаны да инвалид артистлар куйды. Ветераннар ансамбле вальс әйләнде. Регина Кузнецова башкаруындагы “Яшьлегем чишмәләре”, Редьков Александр башкарган “Бәхет кошы” җырларын тамашачы көчле алкышларга күмде. Журналистлар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе, язучы Рахман Шафигуллин, танылган язучы Ягъсуп Шафиков, ТИСБИдан Рәис Нәҗиповларның җылы сүзләре дә Рәкит күңеленә май булып яткандыр. Башкорт ансамбле “Гөлнәзирә” матур җырлар бүләк итте, кичәне алып баручы Эльвира Һадиева өздереп шаян бию башкарды (Эльвираның яраткан укучыларымның берсе икәнен әйтеп тормыйм инде)... Гомумән, Рәкит үзенә генә түгел, барлык инвалидлар өчен дә олы бәйрәм ясады. Чын иганәче икәнсең, дустым!

**Зәбир ХӘЛИМОВ**